КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 25 август г.Казань № 631

2025 – 2027 елларда дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның Татарстан Республикасы территориясендә модульле капиталь булмаган урнаштыру чараларын булдыру буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү һәм (яисә) каплау максатларында аларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Туризм үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2021 елның 24 декабрендәге 2439 номерлы карары белән расланган «Туризм үсеше» Россия Федерациясе дәүләт программасының 19 нчы кушымтасында бирелгән 2025 – 2027 елларда модульле капиталь булмаган урнаштыру чараларын булдыру буенча инвестиция проектларына дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2025 – 2027 елларда дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның Татарстан Республикасы территориясендә модульле капиталь булмаган урнаштыру чараларын

булдыру буенча инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү һәм (яисә) каплау максатларында аларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин